Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль
бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
"Академик Р. З. Сәгъдиев исемендәге гомуми белем бирү мәктәбе»



(1825-1902)

# Каюм Насыйриның тәрбияви әсәрләренең берсе – “Китаб-әт-тәрбия”

**(14 февраль 2025нче ел - күренекле энциклопедист галим Каюм Насыйри туына 200 ел уңаеннан).**

ttps://www.litres.ru/book/kaum-nasyri/kitab-t-t-rbiya-kniga-o-vospitanii-68279747/chitat-onlayn/

Башкарды: 10 нчы сыйныф укучысы
**Әхмәтҗанова Зилә Иршат кызы**.
Җитәкче: **Еремеева Фирания Рәшит кызы.**

# Тормыш юлы

**Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров 1825 елның 2(14) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында укымышлы мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне әтисеннән ала. 1841 – 1855 елларда Казанда мәдрәсәдә укый. Гарәп, фарсы телләрен өйрәнә. Духовная семинариядә эшли.  1885 елда К.Насыйри Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы итеп сайлана. К.Насыйри күбрәк Казанда яши. К.Насыйри китапларын үзе төпләгән, көнкүреш әйберләре ясаган. “Һаман утырып язу ялыктыра, каннар оеша, мин һәр көн бер – ике сәгать эшләп, бу кораллар белән үземә кирәкле әйберләр ясыйм”, - дип әйтә торган булган. Ул рәсем ясаган, географик карталар сызып, календарьларына урнаштырган. К.Насыйри халык медицинасыннан файдаланган, төрле үләннәр белән дәваланган, физик хезмәт белән шөгыльләнгән. Шуның нәтиҗәсе буларак, бөтенләй диярлек ятып авырмаган. К.Насыйри 1902 елның 20 августында (2 сентябрендә) 77 яшендә вафат була, Казанда Яңа бистә ягындагы каберлеккә күмел.**

**ә**

# Эшләгән өлкәләре:

- татар әдәбияты ("Кырык вәзир кыйссасы", "Буш вакыт", "Кырык бакча", "Әбүгалисина", "Фәвакиһел җөласа фил-әдәбият")
- татар теле ("Дөрес һәм матур язу кагыйдәләре", "Әл-мүзәҗ", икетомлык - татар теленең аңлатмалы сүзлеге, татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр);
- этнография;
- фольклор;
- педагогика һәм методика ("Әхлак рисаләсе", "Утыз вәгазь", "Китап әт-тәрбия");
- астрономия;
- математика ("Хисаплык", "Гыйльме һәмдәсә");
- география ("Истилаһәте җәгъръфия")
- физиология;
- ботаника;
- слесарьлык эше;
- кулинария;
- журналистика

# Казанда Каюм Насыйри музее. Экспозициядән  күренешләр.








К.Насыйри һәм татар мәгърифәтчеләре



К.Насыйриның кулдан язылган китабы һәм пичәте. XIX гасыр уртасы

# Казанда К.Насыйри исемендәге урам









## Яшел Үзән районы Олы Ачасыр авылындагы Каюм Насыйри исемендәге архитектура этнография комплексы



**Каюм Насыйри исемендәге архитектура-этнография комплексы мәгърифәтче Каюм Насыйриның туган авылы Шырданнан 7 чакрым ераклыкта Олы Ачасыр авылында урнашкан. Комплекс 1997 елның 1 мартында ачылган һәм ул XIX гасыр ахыры XX гасыр башында яшәгән урта хәлле крестьян тормыш-көнкүрешен сурәтли.**

**Музейда 460 ка якын экспонат бар. Шулай ук К.Насыйриның үз кулы белән ясалган 3 экспонат саклана. Алар: сәке, күн белән тышланган диван, шкаф-секретер.**

# К.Насыйриның үз кулы белән ясаган шкаф-секретеры һәм диваны





# Каюм Насыйри исемендәге премия




**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 елның 19 нчы июненнән һәм 2010 елның 30 нчы декабреннән кабул ителгән "Каюм Насыйри исемендәге премия турында"гы 396 һәм 1141 нче номерлы карарлары нигезендә педагогик коллективларга, мәктәпкәчә белем бирү, гомуми урта, башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренә ел саен Каюм Насыйри исемендәге премия бирелә.**

# Каюм Насыйриның тәрбияви әсәрләренең берсе – “Китаб-әт-тәрбия”

https://www.litres.ru/book/kaum-nasyri/kitab-t-t-rbiya-kniga-o-vospitanii-68279747/chitat-onlayn/

